**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы**
**Карар**

№ 40 21 апрель 2017 ел

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы Президиумының «муниципаль норматив реестрларны алып бару турында» 2016 елның 13 октябрендәге ПР-26-4 номерлы карарын исәпкә алып Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы Җирле үзидарә органнары кабул иткән норматив хокукый актларның норматив хокукый базасын камилләштерү, аларны исәпкә алуны унификацияләү һәм системалаштыру максатларында карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксбай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруга вәкаләтле вәкил итеп Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын билгеләргә тиеш.

3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән җирле үзидарә органнарына һәм аларның вәкаләтле затларына әлеге карарның 1 пунктында расланган актка ярашлы рәвештә:

1) 2017 елның 01 июленә кадәр муниципаль норматив хокукый актлар реестрын формалаштырырга һәм аларны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга;

2) муниципаль норматив хокукый актлар реестрын алып баруны һәм аларны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтындагы җирлек бүлегендә актуаль хәлдә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә муниципаль норматив хокукый актлар реестрын актуаль хәлдә тоту, шулай ук үз вакытында үзгәрешләр кертүне тәэмин итү, законнарга туры килмәгән муниципаль норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану максатларында эш алып бару һәм документлар әйләнеше өчен җаваплы буйсынучы бүлекчәләргә (затларга) йөкләргә, Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитетына муниципаль норматив хокукый актларга (массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгу, суд актлары, контроль яки күзәтчелек органнарының реакция актлары, хокукый экспертиза нәтиҗәләре һәм башкалар турында) килгән көнне яки күрсәтелгән срокка тапшыру мөмкин булмаган очракта, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча килгән мәгълүматны тапшыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы: М.М.Сулейманкин